**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от ______________ ПР-237 02.11.2024 № ________

**2024 елның 5 ноябреннән халыкка тәкъдим ителә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьяларына, «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 2023 елның 14 декабрендәге 867 номерлы ТР Рәисе Указы, «2024 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында үзләренең гомуми җыелышында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексы турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 27 декабрендәге ПР-295 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 5 ноябреннән расларга һәм гамәлгә кертергә:

Актаныш муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар, 1 нче кушымта нигезендә;

Муниципаль торак фондыннан торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү) түләү күләме, 2 нче кушымта нигезендә;

Торак урын милекчеләренең капиталь ремонт өчен түләү күләме, 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2024 елның 12 июленнән халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 15 июлендәге ПР-129 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 5 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына _____ 2024 ел, №___
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы халкына күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Түләү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| | | | Актаныш күпфатирлы йортлар |
| | **Торак бина өчен түләү** | | |
| 1 | Торак йорт белән идарә итү | кв. м./сум | 3,55 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру | кв. м./сум | 4,28 |
| 3 | Торак бинага агымдагы ремонт | кв. м./сум | 4,08 |
| 4 | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | кв. м./сум | 0,37 |
| 5 | сантехчелтәрләрне агымдагы ремонтлау | кв. м./сум | 2,00 |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә агымдагы ремонт | кв. м./сум | 1,06 |
| 7 | Дератизация | кв. м./сум | 0,21 |
| 8 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә хезмәт күрсәтү | кв. м./сум | 0,30 |
| 9 | Торак йортны карап тотуга электр белән тәэмин итү | кв. м./сум | 0,80 |
| 10 | Үзәк җылытуны агымдагы ремонтлау (Механизаторлар 7, Төзүчеләр 3) | кв. м./сум | 1,49 |
| | Барлыгы | | 18,14 |

Киров исемендәге совхоз торак пунктында күпфатирлы йортлар өчен сыек көнкүреш калдыклары чыгару хезмәте күрсәтү тарифы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | кв. м./сум | 3,45 |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына _________ 2024 ел, №___
2 нче кушымта

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәм. | Түләү күләме, сум. |
|---|---|---|---|
| 1. | Найм буенча база ставкасы | аена 1 кв. м. торак бинаның гомуми мәйданы өчен | 6,95 |

Муниципаль торак фондының торак урынынnan файдаланган өчен
түләү күләме (наем өчен түләү)

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына ________ 2024 ел, №____
3 нче кушымта

Торак урын милекчеләренең капиталь ремонт өчен түләү күләме

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| Капиталь ремонт | аена торак урынның гомуми мәйданы кв. м | 6,95 |